

## Габдулла Кариев - татар театрының атасы

*Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,*
*Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.*
*Театр — яктылыкка, нурга илтә,*
*Кире юлга җибәрми, уңга илтә.*

**Г. Тукай “Театр”**



# Ильяс Кудашев-Ашказарский

*Основателем первой профессиональной татарской театральной труппы является Оренбургский учитель, многогранная личность Ильяс Кудашев-Ашказарский. Со спектаклем по пьесе Александра Островского "В чужом пиру похмелье" в переводе на татарский язык труппа впервые выезжает на гастроли по городам России.*









1907 нче елда Габдулла Кариев Түбән Новгородта булачак “Сәйяр“ артистлары белән очраша, бу очрашу аның язмышын хәл итә: ул татар профессиональ театрына нигез салучы, аның беренче артисты, режиссеры булып тарихка кереп кала.

# Сахибжамал Гиззатуллина - Волжская



В 1907 году в труппу пришла Сахибжамал Гиззатуллина-Волжская, первая женщина, взошедшая на сценические подмостки не только в театрах тюркоязычных народов, но и во всём мусульманском мире.

**Татар театрының атасы Габдулла Кариев, Морасаның тәмле суларын эчеп, мәдрәсәсендә белем алган кеше.**

**Колбай-Мораса авылы – саф татар авылы. Элеккеге Чистай өязе Колбай-Мораса авылының Хәйрулла исемле ярлы крестьян гаиләсендә 1886 нчы елның 8 нче маенда бер малай дөньяга килә. Аңа Миңлебай дип исем кушалар. Ул 7 яшьтән 12 яшенә кадәр туган авылы мәдрәсәсендә белем алганнан соң, 1899 нчы елда Такталы мәдрәсәсендә укый башлый. Миңлебай шулкадәр зирәк бала була ки, 12 яшендә Корьәнне яттан белә. Ягъни ул карый була. Мондый зирәк баланың Миңлебай дигән “мужик« исеме йөртүе Такталы авылы мәдрәсәсенең мөдәррисе Зариф муллага бер дә ошамый. Ул үзенең яраткан шәкертенә Габдулла ( алла колы ) исеме бирә. Халык арасында да ул Габдулла карый исеме белән йөртелә башлый. Шушы чордан Миңлебай гомеренең ахырынача Габдулла булып китә.Соңрак фамилиясен Кариевка алыштыра.**



Үз иҗатында театрга реформа ясаучы, яңа юнәлеш бирүче режиссерлар бар. Алар күп түгел. Болар – К. С. Станиславский, Е.Б.Вахтангов, В. Э. Мейерхольд. Ә татар театрын тудырган, аны җитәкләп үстергән Габдулла Кариев та әнә шундый. Кариевның режиссерлыгы шул: ул бер үк вакытта спектакль куючы, тәрбияче, театрның иҗади юнәлешен билгеләүче.

*«Син кояш идең, ләкин вакытсыз сүндең, шулай да синең җылың белән тәрбияләнеп үскән орлыклар көннән-көн артачаклар. Синең хезмәтең, гайрәтең җимешләре исемеңне мәңге онытырмаячаклар»*





***Без шундый театр төзербез,***
***Аның исеме***
***Алтын хәрефләр***
***Белән язылыр!***

*Габдулла Кариев*

*“Несмотря на различные преследования и притеснения... Кариев свое детище – труппу “Сайяр” – поднял на уровень театров других национальностей, столетиями находившихся в более привилегированном положении...”*

Син һәрвакыт юлда... халык белән:
Салкын кышны, эссе җәйләрен.
Рәхмәт сиңа, безнең уйны-хисне
Тамашачы белән бәйләдең.
Син һәрвакыт юлда... халык белән,
Тормыш үзәгеннән киләсең,
Син фаҗига булып кайгырасың,
Комедия булып көләсең.

